| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2014 Казан ш. № 6-75/тп

***Казан шәһәре «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән салкын су бирү системасына тоташу (технологик тоташу) тарифларын билгеләү турында***

“Җылылык белән тәэмин итү һәм су бүлү турындагы” 7.12.2011 ел № 416-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Су бирү һәм су бүлү өлкәсендәге тарифларны дәүләти көйләү турындагы” 13.05.2013 ел № 406 карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Салкын су бирү һәм су бүлү кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турындагы” 29.07.2013 ел № 644 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның “Су бирү һәм су бүлү өлкәсендәге көйләүле тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” 27.12.2013 ел № 1746-э боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Казан шәһәре «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән салкын су бирү системасына тоташу (технологик тоташу) тарифларын шушы карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар аны рәсми игълан итү көненнән соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 28.11.2014 № 6-75/тп
карарына кушымта

# Казан шәһәре «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең үзәкләштерелгән салкын су бирү системасына тоташу (технологик тоташу) тарифлары

| Т. № | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташуга тарифлар (НДСны исәпләмичә) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырылучы йөкләнеш тарифына база ставкасы | мең сум/м$^3$ | 6,606 |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына база ставкасы | мең сум/м | 15,791 |
| 3. | Тарифның челтәрләр диаметрына карата дифферентлашу коэффициенты: | | |
| 3.1. | 40 мм һәм кечерәк диаметрлы | - | 0,37 |
| 3.2. | 40-70 (тулаем) мм диаметрлы | - | 0,54 |
| 3.3. | 70-100 (тулаем) мм диаметрлы | - | 0,59 |
| 3.4. | 100-150 (тулаем) мм диаметрлы | - | 0,63 |
| 3.5. | 150-200 (тулаем) мм диаметрлы | - | 0,67 |
| 3.6. | 200-250 (тулаем) мм диаметрлы | - | 0,75 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге